**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.04.2020 № 201

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2013 ел, 30 декабрь, 1251 нче карарына үзгәрешләр
кертү турында

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының “Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча Озак вакытка исәпләнгән программасын раслау турында” 2013 ел, 3 май, 1251 нче карарына Озак вакытка исәпләнгән программаны яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә (теркәлә).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л. Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 апрелендәге 201 номерлы карары белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШКАН КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДАГЫ ГОМУМИ МИЛЕКНЕ КАПИТАЛЬ РЕМОНТЛАУ БУЕНЧА ОЗАК ВАКЫТКА ИСӘПЛӘНГӘН ПРОГРАММАСЫ**

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча озак вакытка исәпләнгән программасы<br>(алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү турында карар кабул итү өчен нигезләмә | Россия Федерациясе Торак кодексы, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерүне оештыру турында”гы 2013 елның 25 июнендәге 52 нче Законы (алга таба – Закон) |
| Программаны эшләүче | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм сыйфатын арттыру;<br>Гражданнарга имин һәм уңайлы яшәү шартлары тудыру |
| Программаның бурычлары | Халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;<br>Башкарма программаны сайлап алу буенча ачык һәм ачык процедураларны эшләү һәм үтәү;<br>Озак сроклы материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә эффектив техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны куллану |
| Программаны реализацияләү вакыты | 2014-2043 еллар |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Торак фондын Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерү (шул исәптән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, техник җайга салу, кулланучылар хокукларын яклау турында) |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты программаны тормышка ашыруны контрольдә тота |

## I. Мәсьәләнең тасвирламасы

Әлеге Программаны кабул итү өчен күп кенә социаль-икътисадый факторлар алшарт булып тора. Социаль факторлар - яшәү шартларының түбән булуы һәм торак фонд объектларының жимерек хәлдә булуына, ә икътисадый факторлар – аларны тотуга чыгымнарның югары булуына бәйле.

Әлеге проблемаларны хәл итү «Россия гражданнарына – арзан һәм уңайлы торак» милли проектының Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында өстенлекле юнәлеше булып тора һәм әлеге программаны гамәлгә ашыру вакытында оештыру, җитештерү, социаль-икътисади һәм башка чаралар комплексын үткәрү, программаны башкаручыларның эшчәнлеген дәүләт заказчысы тарафыннан тулысынча координацияләнгән очракта гына мөмкин булачак.

## II. Программаның төп максат һәм бурычлары, реализацияләү вакыты һәм Программа үтәлешеннән көтелгән күрсәткечләр

Программаның төп максатлары:

сохранение, восстановление и повышение качества жилищного фонда в Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районындагы торак фондының сакланышын тәэмин итү, яңарту һәм сыйфатын яхшырту;

халыкка яшәү өчен куркынычсыз һәм кулай шартлар тудыру.

Программаның бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Программаны башкаручыларны сайлап алу процедураларын ачык һәм халыкка билгеле булырлык итеп үткәрү;

нәтиҗәле техник карарлар кабул итү һәм капиталь төзекләндерү барышында озакка чыдый торган материаллар, ресурсны саклый торган технологияләрнең комплекслы кулланылуына ирешү.

Әлеге Программа 2014-2043 елларда гамәлгә ашырылачак.

Программаны тормышка ашыру 355 күпфатирлы йортта гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге программаның үтәлешенең планлаштырылган күрсәткечләре аңа Кушымтада тәкъдим ителгән.

## III. Күпфатирлы йортларны Программага кертү шартлары

Программага Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш, кертелә.

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау чираты программада законда күрсәтелгән критерийлар нигезендә билгеләнә.

## IV. Программа чаралары

Программаның төп чаралары:

1. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча түбәндәге хезмәтләр һәм (яки) эшләр башкару:

торак биналарда булган электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак биналарда булган җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алыштыру;

файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазларын ремонтлау яки алыштыру, лифт шахталарын ремонтлау, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазлау;

түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляцияләнми торган түбәне төзекләндерү, түбәгә чыгу юлларын урнаштыру;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау;

фасадны җылыту һәм ремонтлау, керү төркемнәрен пандуслар һәм баскычларны култыксалар белән тәэмин итү, халыкның аз мобильле төркемнәре өчен күпфатирлы йортта гомуми милектән файдалана алуны тәэмин итү максатларында ике яктан да култыксалар белән тәэмин итү;

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслардан файдалануны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануны көйләү һәм идарә итү узелларын урнаштыру яисә алмаштыру;

күпфатирлы йорт нигезен ремонтлау; күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау;

күпфатирлы йортта энергетик тикшерүләр үткәрү;

проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру (проект документациясен әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта);

төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

күпфатирлы йортны янгынга каршы яклау системасын ремонтлау;

күпфатирлы йортларга техник инвентарьлаштыру эшләрен башкару һәм техник паспортлар әзерләү;

күпфатирлы йортларда гомуми милек составына керми торган, ремонтлана торган (алыштырыла торган) конструкцияләрнең һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында демонтажланган яки җимерелгән мөлкәт өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерүне торгызу;

2014 елның 1 июненә кадәр урнаштырылган күпфатирлы йортларда коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру (алмаштыру).

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр башкару озак сроклы һәм экономияле материаллар кулланып, яхшыртылган эксплуатация характеристикалары белән гамәлгә ашырыла.

2. Программаны мәгълүмат белән тәэмин итү, үткәрелә торган процедураларның ачыклыгын, үтә күренмәлелеген тәэмин итү:

Район массакүләм мәгълүмат чараларында (вакытлы матбугатта, газеталарда, журналларда, шул исәптән электрон басмаларда, радио – һәм телеканалларда) программаны гамәлгә ашыру барышын даими яктырту);

торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыру һәм капиталь төзекләндерү турындагы мәсьәләләрне яктырту максатында махсус теле-радиотапшырулар эшләү;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты рәсми сайтын актуаль хәлдә тоту;

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча тематик методик һәм белешмә материаллар чыгару һәм тарату;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары, идарәче оешмалар тарафыннан гражданнарга күпфатирлы йортка капиталь ремонт эшләрен башкаруның планлаштырылган вакыты (программага кертелгән күпфатирлы йортның һәр подъездында урнашкан игъланнар такталарында яки мондый йорт урнашкан җир кишәрлеге чикләрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтларында тиешле мәгълүмат урнаштыру (булганда) турында мәгълүмат җиткерү.

## V. Программаны гамәлгә ашыру тәртибе

Әлеге программаны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын (алга таба – программаны тормышка ашыруның кыска сроклы планнары) бер елга раслый.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ел да раслана торган Программаны тормышка ашыру буенча кыска сроклы (еллык) планнар хәзерләү һәм раслау Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча озак вакытка исәпләнгән программасын раслау тәртибе нигезендә башкарыла.

## VI. Программага үзгәрешләр кертү тәртибе

Программаны актуальләштерү елга бер тапкырдан да сирәгрәк булырга тиеш түгел.

Программаны актуальләштерү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Программага кертелгән күпфатирлы йортның Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аварияле һәм сүтелергә тиеш дип билгеләнүе;

программага кертелгән күп фатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә тартып алуны гамәлгә ашыру, әлеге күпфатирлы йорттагы һәр торак бинаны алу;

яңа күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыру;

программага кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеген үзгәртү;

программага кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срокларын үзгәртү;

программага үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә торган башка нигезләр.

Капиталь ремонтның озак сроклы программасына күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлауның билгеләнгән срогын соңрак вакытка күчерү, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләре исемлеген кыскартуны күздә тоткан үзгәрешләр кертү, законнарда билгеләнгән тәртиптә биналар милекчеләренең гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла.